РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«13» июль 2022г. г. Альметьевск № 154

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 92 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2022 елның 21 апрелендәге 09/13-09/2077 номерлы хатына таянып,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 92 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына» (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 16 декабрендәге 112 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарага 1 нче кушымтада:

1.1. 3 бүлекнең 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Контроль орган «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән белешмәләрне урнаштыру юлы белән «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба - рәсми сайт), массакүләм мәгълүмат чараларында, «Дәүләт мәгълүмат системаларында (алар булган очракта) һәм башка рәвешләрдә контрольдә тотыла торган затларның шәхси кабинетлары аша массакүләм мәгълүмат чараларында «Интернет» челтәрендәге үзенең рәсми сайтында (алга таба - рәсми сайт) урнаштыруны гамәлгә ашыра.»;

1.2. 4 бүлекнең 4.1.3 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турында контроль орган карарын үтәү срогы тәмамлану.

Контроль чаралар, тикшереп тору органының вәкаләтле вазыйфаи затлары

заданиеләре нигезендә, контроль органның эш планнарындагы, шул исәптән «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда, йөкләмәләрне дә кертеп, инспекторлар тарафыннан башкарыла.»;

1.3. 4 бүлекнең 4.4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.3. Планнан тыш контроль чаралар, үзара хезмәттәшлек планы контроль чаралардан тыш, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 1, 3-5 пунктларында каралган нигезләр буенча үткәрелә.»;

1.4. 4 бүлекнең 4.5.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.9. Акт «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә документар тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча контроль органы тарафыннан контроль булган затка җибәрелә.»;

1.5. 4.6.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.13. Күчмә тикшерүне үткәрү контрольдә тотыла торган затның урнашкан (эшчәнлекне гамәлгә ашыру) урыны буенча булмавы сәбәпле яки контрольдә тотыла торган зат эшчәнлегенең факттагы булмавына бәйле рәвештә, яки күчмә тикшерүне уздыру мөмкин булмаган башка гамәлләргә (гамәл кылмауларга) бәйле рәвештә башкарылган очракта, инспектор, сәбәпләрне күрсәтеп, күчмә тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзи һәм контрольдәге затка "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә каралган тәртиптә контроль чаралар уздыру мөмкинлеге булмавы турында хәбәр итә.»;

1.6. 1.6 пунктта «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалык департаменты» сүзләрен «Үсеш департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № п/п | Муниципаль контроль органы исеме | Муниципаль инспектор вазыйфасының атамасы | Телефон |
|---|---|---|---|
| 1. | Муниципальное автономное учреждение «Департамент развития» | Җитештерү буенча директор урынбасары | 8 (8553) 37-55-39 |
| 2. | | Юридик бүлек җитәкчесе | 8 (8553) 37-55-21 |
| 3. | | Әйдәп баручы белгеч | 8 (8553) 37-55-21 |
| 4. | | Җитештерү-техник бүлеге җитәкчесе | 8 (8553) 37-55-24 |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту район Советының икътисади үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мингазов И.М.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»